ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-РӘҖӘП АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

22.09.2020 КАРАР № 2

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 09 сентябрендэге 60-1 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 09 сентябрендэге 60-1 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.11 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында «җирлек халкы өчен» сүзләрен өстәргә.

1.2. 8.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гражданнардан сорашып белешү үткәрү өчен җирлекнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты файдаланылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны Иске-Рәҗәп авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spassriy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Нугаев